| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Об образовании Организационного комитета по подготовке и проведению в 2026 году в городе Казани Международного форума потребительской кооперации «Молодежь кооперации: объединяя ресурсы для развития отрасли»**

В целях организации взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организаций и общественных объединений при подготовке и проведении с 8 по 10 июля 2026 года в городе Казани Международного форума потребительской кооперации «Молодежь кооперации: объединяя ресурсы для развития отрасли» **постановляю**:

1. Образовать Организационный комитет по подготовке и проведению в 2026 году в городе Казани Международного форума потребительской кооперации «Молодежь кооперации: объединяя ресурсы для развития отрасли».

2. Утвердить Положение об Организационном комитете по подготовке и проведению в 2026 году в городе Казани Международного форума потребительской кооперации «Молодежь кооперации: объединяя ресурсы для развития отрасли» (приложение № 1) и его состав (приложение № 2).

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

**Раис Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
14 октября 2025 года
№ 858

Приложение № 1
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «14» октября 2025 года

№ 858

**Положение**
**об Организационном комитете по подготовке и проведению в 2026 году в городе Казани Международного форума потребительской кооперации «Молодежь кооперации: объединяя ресурсы для развития отрасли»**

## I. Общие положения

1. Организационный комитет по подготовке и проведению в 2026 году в городе Казани Международного форума потребительской кооперации «Молодежь кооперации: объединяя ресурсы для развития отрасли» (далее соответственно – Организационный комитет, Международный форум) является коллегиальным органом, образованным в целях организации взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организаций и общественных объединений при подготовке и проведении Международного форума.

2. Организационный комитет в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

## II. Основные задачи Организационного комитета

3. Основными задачами Организационного комитета являются:

а) разработка и утверждение плана мероприятий по подготовке и проведению Международного форума;

б) анализ хода реализации планов, программ и отдельных мероприятий, связанных с подготовкой к проведению Международного форума, обеспечение контроля за выполнением плана мероприятий по подготовке и проведению Международного форума;

в) разработка предложений по организации взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов

федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организаций и общественных объединений в процессе реализации принятых Организационным комитетом решений и оценка их эффективности;

г) организация взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организаций и общественных объединений при решении задач, связанных с выполнением плана мероприятий по подготовке и проведению Международного форума.

4. Организационный комитет в целях реализации стоящих перед ним задач имеет право:

а) запрашивать и получать в соответствии с законодательством от органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организаций и общественных объединений информационные материалы по вопросам, относящимся к компетенции Организационного комитета;

б) создавать в установленном порядке рабочие группы для решения вопросов, относящихся к компетенции Организационного комитета;

в) утверждать официальную символику, дизайн и паспорт визуальных стандартов построения и использования элементов официального и делового стиля Международного форума;

г) приглашать в установленном порядке на свои заседания руководителей и иных представителей органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организаций, общественных объединений и прочих заинтересованных лиц;

д) направлять своих представителей для участия в совещаниях, конференциях и семинарах по вопросам подготовки и проведения Международного форума.

## III. Состав Организационного комитета

5. Состав Организационного комитета утверждается Раисом Республики Татарстан.

6. В состав Организационного комитета входят сопредседатели, заместители сопредседателей, секретарь и иные члены Организационного комитета, которые принимают участие в его работе на общественных началах.

7. Сопредседатели Организационного комитета:

а) руководят работой Организационного комитета, определяют перечень, сроки и порядок рассмотрения вопросов на заседаниях Организационного комитета;

б) распределяют полномочия (обязанности) между заместителями сопредседателей и членами Организационного комитета;

в) определяют и утверждают повестку дня, дату, время и место проведения заседаний;

г) подписывают протоколы заседаний и другие документы Организационного комитета.

8. Секретарь Организационного комитета:

а) участвует лично в заседаниях Организационного комитета;

б) уведомляет членов Организационного комитета о месте, дате, времени проведения заседания не менее чем за пять дней до дня проведения заседания, рассылает повестку дня заседания;

в) осуществляет подготовку протоколов заседаний и других документов Организационного комитета.

9. Члены Организационного комитета:

а) участвуют лично в заседаниях Организационного комитета;

б) выносят на обсуждение предложения по вопросам, находящимся в компетенции Организационного комитета;

в) осуществляют иные мероприятия по подготовке, исполнению решений Организационного комитета.

## IV. Заседания и решения Организационного комитета

10. Заседания Организационного комитета проводятся по мере необходимости.

11. Заседания Организационного комитета ведут сопредседатели либо один из сопредседателей.

12. Заседание Организационного комитета считается правомочным, если в нем принимают участие более половины его членов. Решение Организационного комитета считается принятым, если за него проголосовало не менее половины членов, присутствующих на заседании. По результатам рассмотрения вопросов повестки дня и голосования на заседании Организационного комитета принимаются решения, которые оформляются протоколом. Протокол заседания Организационного комитета подписывается сопредседателями либо одним из сопредседателей.

13. Решения, принимаемые Организационным комитетом, доводятся до заинтересованных органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан, организаций и общественных объединений, иных заинтересованных лиц для руководства при осуществлении текущей деятельности.

## V. Обеспечение деятельности Организационного комитета

14. Организационно-техническое, документационное, информационное и иное обеспечение деятельности Организационного комитета осуществляется Министерством сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан во взаимодействии с Центральным союзом потребительских обществ Российской Федерации.

Приложение № 2
к Указу Раиса
Республики Татарстан

от «14» октября 2025 года

№ 858

**Состав**
**Организационного комитета по подготовке и проведению в 2026 году в городе Казани Международного форума потребительской кооперации «Молодежь кооперации: объединяя ресурсы для развития отрасли»**

| | |
|---|---|
| Зубов<br>Дмитрий Львович | председатель Совета Центрального союза потребительских обществ Российской Федерации, сопредседатель Организационного комитета (по согласованию) |
| Гафаров<br>Шамиль Хамитович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – Руководитель Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан, сопредседатель Организационного комитета |
| Бродский<br>Виталий Александрович | заместитель председателя Совета Центрального союза потребительских обществ Российской Федерации, заместитель сопредседателей Организационного комитета (по согласованию) |
| Зяббаров<br>Марат Азатович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан, заместитель сопредседателей Организационного комитета |
| Набиева<br>Алсу Рустэмовна | член Совета Центрального союза потребительских обществ Российской Федерации, ректор автономной некоммерческой образовательной организации высшего образования Центросоюза Российской Федерации «Российский университет кооперации», секретарь Организационного комитета (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Абашев Альмир Рашидович | министр здравоохранения Республики Татарстан |
| Аюпова Ирада Хафизяновна | министр культуры Республики Татарстан |
| Бекетова Мария Борисовна | председатель Правления Центрального союза потребительских обществ Российской Федерации (по согласованию) |
| Белоусов Олег Алексеевич | заместитель председателя Правления Центрального союза потребительских обществ Российской Федерации (по согласованию) |
| Вахитов Радик Рафикович | представитель Министерства иностранных дел Российской Федерации в городе Казани (по согласованию) |
| Воронцов Андрей Юрьевич | начальник контрольно-пропускного пункта «Казань-аэропорт» отряда пограничного контроля «Поволжье» Пограничного управления Федеральной службы безопасности Российской Федерации по Саратовской и Самарской областям (по согласованию) |
| Габдрашитов Булат Рашитович | начальник Управления государственного протокола Раиса Республики Татарстан |
| Гайнуллов Рустем Рафаилович | заместитель министра сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан |
| Гараев Марат Масгутович | начальник Татарстанской таможни Приволжского таможенного управления Федеральной таможенной службы (по согласованию) |
| Гафаров Рустем Гильфанович | руководитель Исполнительного комитета муниципального образования города Казани (по согласованию) |
| Денисов Максим Сергеевич | генеральный директор автономной некоммерческой организации «Дирекция спортивных и социальных проектов» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Зарипов<br>Ильдус Фатихович | глава муниципального образования «Лаишевский муниципальный район» (по согласованию) |
| Кадамов<br>Ирек Ильгизович | начальник Главного управления Министерства Российской Федерации по делам гражданской обороны, чрезвычайным ситуациям и ликвидации последствий стихийных бедствий по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Кадыров<br>Азат Рифгатович | министр по делам молодежи Республики Татарстан |
| Коробченко<br>Олег Владимирович | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр промышленности и торговли Республики Татарстан |
| Кузьмина<br>Лариса Ильдусовна | член Совета Центрального союза потребительских обществ Российской Федерации, председатель Совета Оренбургского областного союза потребительских обществ (по согласованию) |
| Миннегалиев<br>Роберт Хамитович | генеральный директор автономной некоммерческой организации «Центр развития и поддержки конгрессно-выставочных, культурных, зрелищно-развлекательных, спортивно-массовых и социально ориентированных мероприятий «Казань Экспо» (по согласованию) |
| Нафигин<br>Альберт Ильдарович | помощник Раиса Республики Татарстан |
| Патяшина<br>Марина Александровна | руководитель Управления Федеральной службы по надзору в сфере защиты прав потребителей и благополучия человека по Республике Татарстан (Татарстан) (по согласованию) |
| Савельев<br>Игорь Леонидович | заместитель Руководителя Администрации Раиса Республики Татарстан – руководитель Экспертного департамента Раиса Республики Татарстан |
| Салимгараев<br>Айдар Саитгараевич | руководитель Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям «Татмедиа» |

| | |
|---|---|
| Сатретдинов Дамир Растямович | Министр внутренних дел по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Файзрахманов Марат Джаудатович | министр финансов Республики Татарстан |
| Фаттерахманов Ленар Рифатович | начальник Управления агропромышленного комплекса, земельных отношений и потребительского рынка Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |
| Хадиуллин Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |
| Ханифов Фарит Мударисович | министр транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан |
| Шаймарданов Рашат Рифкатович | член президиума Совета Центрального союза потребительских обществ Российской Федерации, член Совета Центрального союза потребительских обществ Российской Федерации, председатель правления некоммерческой организации «Союз организаций потребительской кооперации Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Шакирова Лилия Файзрахмановна | заместитель председателя правления по экономике и инвестиционному развитию некоммерческой организации «Союз организаций потребительской кооперации Республики Татарстан» (по согласованию) |

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2026 елда Казан шәһәрендә «Яшьләр кооперациядә: тармакны үстерү мөмкинлекләрен берләштерү» кулланучылар кооперациясе халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзү турында**

«Яшьләр кооперациядә: тармакны үстерү мөмкинлекләрен берләштерү» кулланучылар кооперациясе халыкара форумын әзерләгәндә һәм аны Казан шәһәрендә 2026 елның 8 июленнән 10 июленә кадәр уздыру вакытында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында **карар бирәм:**

1. 2026 елда Казан шәһәрендә «Яшьләр кооперациядә: тармакны үстерү мөмкинлекләрен берләштерү» кулланучылар кооперациясе халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә.

2. 2026 елда Казан шәһәрендә «Яшьләр кооперациядә: тармакны үстерү мөмкинлекләрен берләштерү» кулланучылар кооперациясе халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 14 октябрь
№ 858

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «14» октябрендәге
858 номерлы Указына
1 нче кушымта

**2026 елда Казан шәһәрендә «Яшьләр кооперациядә: тармакны үстерү мөмкинлекләрен берләштерү» кулланучылар кооперациясе халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. 2026 елда Казан шәһәрендә «Яшьләр кооперациядә: тармакны үстерү мөмкинлекләрен берләштерү» кулланучылар кооперациясе халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба тиешенчә – Оештыру комитеты, Халыкара форум) – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең Халыкара форумны әзерләгәндә һәм уздырганда үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган.

2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Оештыру комитетының төп бурычлары

3. Оештыру комитетының төп бурычлары:

а) Халыкара форумны әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планын эшләү һәм раслау;

б) Халыкара форумны үткәрүне әзерләүгә бәйле планнарны, программаларны һәм аерым чараларны гамәлгә ашыру барышын анализлау, Халыкара форумны әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планының үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

в) Оештыру комитеты кабул иткән карарларны гамәлгә ашыру барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча

территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

г) Халыкара форумны әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планын үтәүгә бәйле бурычларны хәл иткәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыру.

4. Оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә Оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

б) Оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзергә;

в) Халыкара форумның рәсми символикасын, дизайнын, рәсми һәм эш стиле элементларын булдыруның һәм аннан файдалануның визуаль стандартлары паспортын расларга;

г) билгеләнгән тәртиптә үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен, аларның башка вәкилләрен һәм кызыксыну белдергән бүтән затларны чакырырга;

д) үз вәкилләрен Халыкара форумны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашырга җибәрергә.

## III. Оештыру комитеты составы

5. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

6. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты рәистәшләре, рәистәшләр урынбасарлары, Оештыру комитеты секретаре һәм Оештыру комитетының башка әгъзалары керә, алар аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша.

7. Оештыру комитеты рәистәшләре:

а) Оештыру комитеты эшенә җитәкчелек итәләр, Оештыру комитеты утырышларында карала торган мәсьәләләр исемлеген, аларны карап тикшерү срокларын һәм тәртибен билгелиләр;

б) рәистәшләр урынбасарлары һәм Оештыру комитеты әгъзалары арасында вәкаләтләрне (вазыйфаларны) бүләләр;

в) утырышларның көн тәртибен, уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгелиләр һәм раслыйлар;

г) Оештыру комитеты утырышлары беркетмәләренә һәм башка документларына кул куялар.

8. Оештыру комитеты секретаре:

а) Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

б) Оештыру комитеты әгъзаларына утырышны уздыру көненә кадәр кимендә биш көн кала утырышны уздыру урыны, датасы, вакыты турында хәбәр итә, утырышның көн тәртибен җибәрә;

в) Оештыру комитеты утырышлары беркетмәләрен һәм башка документларын әзерли.

9. Оештыру комитеты әгъзалары:

а) Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнашалар;

б) Оештыру комитеты компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча фикер алышуга тәкъдимнәр бирәләр;

в) Оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыралар.

## IV. Оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

10. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.

11. Оештыру комитеты утырышларын рәистәшләр яисә рәистәшләрнең берсе алып бара.

12. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, эш алып барырга хокуклы дип санала. Оештыру комитеты карары, әгәр аның өчен утырышта катнашкан әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Оештыру комитеты утырышында көн тәртибендәге мәсьәләләрне карап тикшерү һәм тавыш бирү йомгаклары буенча карарлар кабул ителә, алар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә рәистәшләр яисә рәистәшләрнең берсе кул куя.

13. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, кызыксынган башка затларга эшчәнлек алып барганда куллану өчен җиткерелә.

## V. Оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

14. Оештыру комитеты эшчәнлеген оештыру-техник яктан, документлар, мәгълүмат белән һәм башкача тәэмин итүне Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлеге белән хезмәттәшлектә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы башкара.

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «14» октябрендәге
858 номерлы Указына
2 нче кушымта

**2026 елда Казан шәһәрендә «Яшьләр кооперациядә: тармакны үстерү мөмкинлекләрен берләштерү» кулланучылар кооперациясе халыкара форумын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Зубов<br>Дмитрий Львович | Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлеге советы рәисе, Оештыру комитеты рәистәше (килешү буенча) |
| Гафаров<br>Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Оештыру комитеты рәистәше |
| Бродский<br>Виталий Александрович | Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлеге советы рәисе урынбасары, Оештыру комитеты рәистәшләре урынбасары (килешү буенча) |
| Җәббаров<br>Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, Оештыру комитеты рәистәшләре урынбасары |
| Нәбиева<br>Алсу Рөстәм кызы | Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлеге советы әгъзасы, Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлегенең «Россия кооперация университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган мәгариф оешмасы ректоры, Оештыру комитеты секретаре (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Абашев<br>Альмир Рәшит улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бекетова<br>Мария Борисовна | Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлеге идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Белоусов<br>Олег Алексеевич | Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлеге идарәсе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Вахитов<br>Радик Рафикъ улы | Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Воронцов<br>Андрей Юрьевич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча чик буе идарәсе «Идел буе» чик буе контроле отрядының «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пункты башлыгы (килешү буенча) |
| Габдерәшитов<br>Булат Рәшит улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт протоколы идарәсе башлыгы |
| Гайнуллов<br>Рөстәм Рафаил улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары |
| Гәрәев<br>Марат Мәсгут улы | Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Гаффаров<br>Рөстәм Гыйльфан улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Денисов<br>Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зарипов<br>Илдус Фатыйх улы | «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Кадәмов<br>Ирек Илгиз улы | Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Кадыйров<br>Азат Рифгать улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Коробченко<br>Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Кузьмина<br>Лариса Илдус кызы | Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлеге советы әгъзасы, Оренбург өлкәсе кулланучылар җәмгыятьләре берлеге советы рәисе (килешү буенча) |
| Миңнегалиев<br>Роберт Хәмит улы | «Казан Экспо» конгресс-күргәзмә, мәдәни, тамаша-күңел ачу, спорт-массакүләм һәм социаль юнәлешле чараларны үстерү һәм аларга ярдәм итү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Нәфыйгин<br>Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе |
| Патяшина<br>Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Савельев<br>Игорь Леонидович | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Садретдинов<br>Дамир Рөстәм улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Фәйзрахманов<br>Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Фәттерахманов<br>Ленар Рифат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шәймәрданов<br>Рашат Рифкать улы | Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлеге советы президиумы әгъзасы, Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлеге советы әгъзасы, «Татарстан Республикасы Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциячел булмаган оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Шакирова<br>Лилия Фәйзрахман кызы | «Татарстан Республикасы Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциячел булмаган оешмасы идарәсе рәисенең икътисад һәм инвестицион үсеш буенча урынбасары (килешү буенча) |